АГЕНТСТВО
ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасының
Инвестицион үсеш
агентлыгы

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**« 19 » мая 2014 г.** № 76/2лс

г. Казань

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча конкурс турында**

2004 елның 27 июленнән № 79 – ФЗ “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында” Федераль закон, 2005 елның № 112 “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләү буенча конкурс турында” РФ Президенты Указы, 2003 елның 16 гыйнварыннан № 3 – ТРЗ “Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законы нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча конкурс үткәрүгә карата конкурс комиссиясе эшенең тәртибен һәм вакытларын расларга (№1 кушымта).

2. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча конкурс үткәрү методикасын расларга (№2 кушымта).

3. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының 2013 елның 15 июленнән № 102/2 лс “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләү буенча конкурс турында” боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Якупов Л.Г.

№1 Кушымта
2014 елның 19 маеннан № 76/2лс
Татарстан Республикасы Инвестицион
үсеш агентлыгы боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча конкурс үткәрүгә карата конкурс комиссиясе эшенең тәртибе һәм вакытлары**

1. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының (алга таба - Агентлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча конкурс үткәрүгә карата конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) үз эшчәнлеген даими нигездә башкара һәм рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2. Конкурс комиссиясенең эшчәнлеген җитәкләү конкурс комиссиясенең рәисе тарафыннан башкарыла. Конкурс комиссиясе рәисе вакытлыча булмаганда (авырганда, командировка, ялда булганда) конкурс комиссиясен җитәкләү конкурс комиссиясе рәисе урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Конкурс комиссиясе эшен тәэмин итүне (гаризаларны теркәү һәм кабул итүне, эшләрне формалаштыруны, конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен алып баруны) Агентлыкның кадрларга бәйле эшләрне алып баруга җаваплы хезмәткәре - конкурс комиссиясе сәркатибе башкара. Конкурс комиссиясе сәркатибе Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны (алга таба – граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы) биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва итүче кандидатларны бәяләүдә катнаша һәм конкурс комиссиясе тарафыннан карар кабул ителгәндә тавыш бирү хокукына ия.

4. Конкурс комиссиясе утырышы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча конкурс (алга таба - конкурс) игълан итү һәм үткәрү турындагы Агентлык җитәкчесе

боерыгы чыгарылганда үткәрелә.

5. Конкурс комиссиясе утырышы дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча кимендә ике кандидат булганда үткәрелә.

Әгәр дә анда кимендә әгъзаларның өчтән ике өлеше катнашса, конкурс комиссиясе утырышы тулы хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик аның дәүләт граждан хезмәтендәге вазыйфаларны биләүче әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.

Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәл иткеч санала.

6. Конкурс комиссиясе конкурсны үткәргәндә катнашучыларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларының дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфасына карата тиешле квалификация таләпләреннән һәм әлеге вазыйфа буенча башка вазыйфаи регламент нигезләмәләреннән, һәм шулай ук Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турындагы законнары белән расланган нигезләмәләрдән чыгып бәяли һәм конкурс җиңүчесе турында карар кабул итә.

7. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән аның утырышында катнашучы әгъзалары тавышының гади күпчелеге белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәл иткеч санала.

8. Конкурс комиссиясе карары дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләүне (кадрлар резервына кертелүне) дәгъвалаучы кандидат катнашыннан гайре кабул ителә һәм аны дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) билгеләү яки моны кире кагуга нигез булып тора.

Конкурс комиссиясе шулай ук дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурста җиңмәгән, әмма профессональ һәм шәхси сыйфатлары югары бәягә лаек булган кандидатны Агентлыкның кадрлар резервына өстәү турында тәкъдим итүче характердагы карарны кабул итә ала.

9. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре карар белән

формалаштырыла, ул утырышта катнашкан рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

10. Конкурс нәтиҗәләре буенча дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфага билгеләү турында яллаучы вәкиле актына чыгарыла һәм конкурс җиңүчесе белән хезмәт контракты төзелә.

Әгәр дә конкурс комиссиясе тарафыннан Агентлыкның кадрлар резервына дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурсның җиңүчесе булмаган кандидатны өстәү карары кабул ителсә, ул вакытта күрсәтелгән зат ризалыгы белән аны Агентлыкның дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфасына караган шул ук төркемнең дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләү буенча кадрлар резервына өстәлүе турында Агентлык боерыгы чыгарыла.

11. Дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә кандидат конкурс комиссиясе карарын Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылуга хокуклы.

№2 кушымта
2014 елның 19 маеннан № 76/2лс
Татарстан Республикасы Инвестицион
үсеш агентлыгы боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча конкурс үткәрү методикасы**

## Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча конкурс үткәрү методикасы (алга таба - методика) Инвестицион үсеш агентлыгында (алга таба - Агентлык) конкурс оештыруны һәм аның тәртибен билгели.

2. Конкурсны үткәрүнең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– дәүләт граждан хезмәтенә тигез мөмкинлекле булуына карата Россия Федерациясе гражданнарының конституция хокукларын яклау,

– дәүләт граждан хезмәте хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсүенә карата хокукларын яклау,

– Агентлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

3. Конкурс дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен, әлеге вазыйфага карата квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән һәм җиңүчене билгеләүдән гыйбарәт.

## Конкурс үткәрүне оештыру

4. Конкурс, аны биләү 2004 елның 27 июленнән № 79 – ФЗ "Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында" Федераль законның 22 статьясы нигезендә конкурс нигезендә башкарылырга мөмкин булган дәүләт граждан

хезмәтендәге вакант (дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан биләнмәгән) вазыйфа булганда Агентлык җитәкчесенең карары буенча игълан ителә һәм Агентлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

5. Агентлыкта конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

а) Агентлыктагы “җитәкче” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләренә дәүләт граждан хезмәтендәге вазыйфа вәкаләтләренә озак вакытка билгеләнгәндә;

б) ашыгыч хезмәт контракты төзелгәндә;

в) Федераль законның 28 статьясының 2 өлеше, 31 статьясының 1 өлеше һәм 60.1 статьясының 9 өлеше белән каралган очракларда граждан хезмәткәрен граждан хезмәтенең бүтән вазыйфасына билгеләгәндә;

д) граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

6. Конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

а) алар буенча вазыйфа бурычларын үтәү дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны файдалануга бәйле, Агентлык боерыгы белән расланучы вазыйфалар исемлеге буенча аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

б) Агентлык җитәкчесе карары буенча граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә караучы граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

7. 18 яшькә җиткән, федераль законнарның, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларының дәүләт граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләү таләпләренә туры килүче Россия Федерациясе гражданнары һәм шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләре конкурста катнаша ала.

Граждан хезмәткәре, гомуми нигезләрдә, конкурсны үткәрү чорында нинди вазыйфаны биләвенә карамастан, конкурста катнашу хокукына ия.

8. Конкурс ике этапта үткәрелә. Беренче этапта, Агентлыкның һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларында конкурста катнашу буенча документлар кабул ителү турында игълан урнаштырыла, һәм шулай ук конкурс турындагы түбәндәге мәгълүматлар җиткерелә: граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаның исеме, әлеге вазыйфага дәгъва кылучыга булган таләпләр, граждан

хезмәтен үтүнең шартлары, конкурста катнашу өчен кирәкле документлар исемлеге, аларны кабул итүнең урыны һәм вакыты, әлеге документларны кабул итүнең тәмамлану вакыты, конкурсны үткәрүнең ниятләнгән көне, урыны һәм аны үткәрү тәртибе, башка мәгълүмат материаллары. Конкурста катнашу буенча документлар кабул итү турындагы игълан һәм конкурс турындагы мәгълүмат басма матбугатта да басылырга мөмкин.

9. Конкурста катнашырга теләк белдерүче гражданин дәүләт органына түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шәхси гариза;

б) формасы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган, үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосурәтен теркәү белән берлектә;

в) паспортның яисә аны алыштыручы документның (тиешле документ конкурска шәхсән килгәндә күрсәтелә) күчермәсе;

г) кирәкле профессиональ белемне, эш стажын һәм квалификацияне раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең (хезмәт (вазыйфа башкару) эшчәнлеге беренче тапкыр тормышка ашырылган очраклардан тыш) яисә гражданинның хезмәт (вазыйфа башкару) эшчәнлеген раслый торган башка документларның күчермәсе;

профессиональ белем алу турындагы документларның, шулай ук гражданинның шәхси теләге буенча – өстәмә профессиональ белем алу турындагы, гыйльми исемнәре турындагы документларының нотариаль яктан яисә хезмәт (вазыйфа башкару) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан рәсмиләштерелгән күчермәләре;

д) гражданинның граждан хезмәтенә куелуына һәм үтүенә комачау итүче чирләре булмавы турында документ;

е) 2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында”гы ФЗ-79 номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте боерыкларында каралган башка документлар.

10. Агентлык хезмәткәре булган граждан хезмәткәре гаризаны җитәкче исеменә тапшыра.

Башка дәүләт органындагы конкурста катнашырга теләк белдергән Агентлыкның граждан хезмәткәре әлеге дәүләт органына эшкә алучы вәкиле исеменә гариза һәм үз кулы белән тутырып һәм имзалап, Агентлыкның кадрлар эшчәнлеген алып бару буенча җаваплы хезмәткәре тарафыннан рәсмиләштереп, фотосурәте белән берлектә, анкетасын тапшыра.

11. Методиканың 9, 10 пунктларында күрсәтелгән документлар Агентлыкка аларны кабул итү турындагы игълан Агентлыкның “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында басылган көннән 21 көн эчендә тапшырыла.

Нигезле сәбәпләрсез документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә яисә рәсмиләштерүдә төгәлсезлекләр җибәреп тапшыру гражданиннан аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Нигезле сәбәпләр булганда, эшкә алучының вәкиле (конкурс комиссиясенең рәисе) аларны кабул итүнең вакытын күчерә ала.

12. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) рөхсәте белән, әгәр дә гражданин (граждан хезмәткәре) дәгъва итүче граждан хезмәтенең вәкаләтле вазыйфаларын башкару дәүләт яисә закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалануга бәйле булса, аңа карата мондый мәгълүматларны рөхсәт итүне рәсмиләштерү процедурасы үткәрелә.

Гражданин тарафыннан җитәкче исеменә тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге тикшерелүгә дучар ителә.

Граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген тикшерү бары тик ул граждан хезмәтенең югары төркемендәге вазыйфаларына карауч граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча конкурста катнашкан очракта гына башкарыла.

13. Граждан хезмәтенең вакант вазыйфасына булган квалификацион таләпләргә туры килмәгәндә, шулай ук Россия Федерациясенең дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарында граждан хезмәтенә алыну һәм аны үтү буенча каралган чикләүләр нигезендә, гражданин (граждан хезмәткәре) конкурска кертелми.

14. Гражданин конкурста катнашуга түбәндәге очракларда кертелми:

1) аны эшкә яраксыз яки чикле рәвештә эшкә яраклы дип тану буенча законлы көченә кергән суд карары белән;

2) аны дәүләт хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи йөкләмәләрне башкаруны чикләүче җәзага тартканда, законлы көченә кергән суд карары буенча, һәм шулай ук алынмаган яисә федераль законда каралган тәртиптә суд хөкеме алынып бетмәгән булса;

3) биләүгә дәгъва иткән граждан хезмәтенең вазыйфасы буенча аны үтәү гражданинның вазыйфаи йөкләмәләренә караган яки граждан хезмәткәре тарафыннан биләнүче граждан хезмәтенең вазыйфалары мондый белешмәләрне файдаланып эшләүгә бәйле булган дәүләт һәм федераль закон белән саклanучы бүтән серне тәшкил итүче сергә кагылышлы белешмәләргә рөхсәт алуны рәсмиләштерү процедураларын узудан баш тартса;

4) граждан хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачау итүче һәм медицина оешмасы бәяләмәсе буенча расланган авыруы булса;

5) граждан хезмәткәре белән якын туганлыкка яки үзгәлеккә (ата-анасы, тормыш иптәше, балалары, ир туганнары, кыз туганнары, һәм шулай ук тормыш иптәшенең ир туганнары, кыз туганнары, ата-анасы, тормыш иптәшләренең балалары һәм тормыш иптәшенең балалары) ия булып, граждан хезмәтендәге биләнәчәк вазыйфа аларның бер-берсе белән турыдан-туры ике арадагы буйсынуга бәйле булса;

6) Россия Федерациясе гражданины булудан туктаса яки башка дәүләт гражданинына әйләнсә;

7) башка дәүләт (башка дәүләтләрнең) гражданлыгына ия булса, әгәр дә башкасы Россия Федерациясе халыкара килешүе белән каралмаган булса;

8) граждан хезмәтенә ялланганда ялган документлар яки белә торып ялган белешмәләр тапшырса;

9) граждан хезмәтенә ялланганда әлеге 27.07.2004 елдан № 79 – ФЗ “Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында” Федераль законда каралган белешмәләрне тапшырмаса яки керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белә торып ялган белешмәләр тапшырса;

10) аңа карата чакырылыш комиссиясе билгеләмәсе нигезендә законлы

нигезләре булмый торып, чакыру буенча хәрби хезмәтне үтмәгән булса (контракт буенча хәрби хезмәт узган гражданнардан кала).

15. Конкурсның икенче этабын үткәрү турындагы карар конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва кылучыларның тапшырган мәгълүматларының дөреслеген тикшергәннән соң, һәм шулай ук, кирәк булганда, дәүләт яки закон тарафыннан саклана торган бүтән серне тәшкил итүче мәгълүматларга үтеп керүгә рөхсәт рәсмиләштерелгәннән соң кабул ителә.

Тикшерү барышында гражданинның граждан хезмәтенә яллануы буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары нигезендә каршы килүче шартлар ачыкланганда, ул бу хакта конкурс комиссиясенең сәркатибе тарафыннан конкурста катнаштырудан баш тартуның сәбәпләрен аңлатып хәбәрләштерелә.

16. Конкурста катнашуга үткәрелмәгән граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва кылучы, әлеге карарны Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә шикаять кыла ала.

17. Конкурс комиссиясенең сәркатибе, конкурсның икенче этабы башланырга 15 көннән дә соңармыйча, конкурста катнашуга кертелгән гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә) (алга таба - кандидатлар) аның үткәрелү көне, урыны һәм вакыты турында хәбәр итә.

18. Әгәр дә граждан хезмәтенең аны биләүгә карата игълан ителгән конкурсны үткәрү нәтиҗәсендә вакант вазыйфасына карата квалификация таләпләренә туры килүче кандидатлар ачыкланмаса, Агентлыкның җитәкчесе конкурсны кабат үткәрү турында карар кабул итә ала.

19. Конкурсның икенче этабында конкурс комиссиясе кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын алар тапшырган белем алу, граждан яки бүтән дәүләт хезмәтен үтү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турындагы документларыннан чыгып, һәм шулай ук федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларына каршы килмәүче конкурс процедуралары (шәхси сөйләшү, анкеталаштыру, төркемле дискуссияләр үткәрү, реферат язу яки граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы буенча вазыйфаи

йөкләмәләрне үтәүгә бәйле сораулар буенча тест үтү) нигезендә бәяли һәм конкурсның җиңүчесе турында карар кабул итә.

20. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән, кандидат катнашыннан гайре, аның утырышында катнашкан әгъзаларының күпчелек тавышыннан чыгып кабул ителә.

21. Конкурс комиссиясе карары кандидатны граждан хезмәтендәге вакант вазыйфага билгеләү яки мондый билгеләүдән баш тарту, яки конкурс җиңүчесе – граждан хезмәткәрен (гражданинны) Агентлыкның кадрлар резервына кертүгә нигез булып тора.

Конкурс комиссиясе шулай ук профессиональ һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган, әмма граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләү буенча конкурс җиңүчесе булмаган кандидатны Агентлыкның кадрлар резервына кертү буенча киңәш итүче карар да кабул итә ала.

**Соңгы нигезләмәләр**

22. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс җиңүчесен граждан хезмәтендәге вакант вазыйфага билгеләү буенча Агентлык боерыгы чыгарыла һәм конкурсның җиңүчесе белән хезмәт контракты төзелә.

Әгәр дә конкурс комиссиясе тарафыннан Агентлыкның кадрлар резервына конкурс җиңүчесе булмаган кандидатны кертү турында карар кабул ителсә, ул вакытта күрсәтелгән затның ризалыгы белән аны граждан хезмәтенең вакант вазыйфасы караган шул ук төркемдәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү буенча Агентлыкның кадрлар резервына кертү буенча Агентлык боерыгы чыгарыла.

23. Конкурс комиссиясе сәркатибе конкурс тәмамланганнан соң 7 көн эчендә аның нәтиҗәләре турында кандидатларга хәбәр итә. Конкурсның нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат шулай ук билгеләнгән вакытка Агентлыкның һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүматы системасының рәсми сайтларында урнаштырыла.

24. Конкурста катнаштырылмаган һәм конкурста катнашкан граждан хезмәтендәге вакант вазыйфаны биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата дәгъва белдерүчеләрнең документлары аларга конкурс тәмамланганнан соң өч ел

эчендә язмача гаризалары буенча кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге вакыт узганчыга кадәр документлар Агентлыкның архивында саклана, соңыннан юк ителә.

25. Конкурста катнашуга бәйле (конкурс үтү урынына килү һәм кире китү, торак бинаны наймга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкалар) чыгымнар кандидатларның үз хисабына каплана.

26. Конкурс комиссиясенең карарын кандидат Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.